# КАРАР

**06 апрель 2024 ел № 6**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 28 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскә авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм «Иске Кырлайавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының 2024 елның 06 апрелендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлеге Югары Мәтәскә авылында «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскәавылында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелгән:

« Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы?

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Югары Мәтәскә авылы, Азин урамы);
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау , төзү һәм ремонтлау (Югары Мәтәскә авылына скважина өчен насос сатып алу- 1данә).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 197 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 100 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 96 кеше тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегендә Югары Мәтәскә авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2.« Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Югары Мәтәскә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 75 яшьтән узган гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы?

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су жыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау , төзү һәм ремонтлау (Югары Мәтәскә авылында су манарасын тоташтыру һәм төзекләндерү, Югары Мәтәскә авылына скважина өчен насос сатып алу- 1данә);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Мәтәскә авылында кече архитектура формаларын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү-1 данә).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга, карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы Югары Мәтәскә авылы, Азин урамы, 31 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы

Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Лутфуллин Ф.Ф.